| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Совет Шарлиареминского**<br>**сельского поселения**<br>**Сармановского муниципального**<br>**района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районының**<br>**Шәрләрәмә авыл җирлеге**<br>**Советы** |

---

**РЕШЕНИЕ** 31.03.2026

**КАРАР** №20

Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»19.11.2014 ел, № 33 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 130 пункты, Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 19.11.2014 ел, № 33 карарына (26.05.2015 ел, № 9, 20.06.2018 ел, № 66, 20.11.2018 ел, № 81, 16.03.2020 ел, № 123, 01.11.2024 № 102 22.11.2024 N 109а, 15.12.2025 № 10 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
2 пункт 2.4.3 пунктчасында «проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш » сүзләрен өстәргә;

2. Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының «Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 19.11.2014 ел, № 33 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 24.02.2026 ел, № 33 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» халыкка җиткерергә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге
Совет рәисе

Н.Н.Хуҗина